Literature

Әдәбият

Литература

DOI: 10.26907/2311-2042-2023-20-1-32-43

# THE SONG "KONGYR BOGA": ITS HISTORICAL ROOTS AND POETICS IN THE CONTEXT OF THE TURKIC PEOPLES'[1] CULTURE

**Naki Isanbet,**
Kazan,
mileuscha@mail.ru.

The object of this study is the dastan "Kongyr Boga" and the Bashkir folk song of the same name. The subject of the study is the history of their creation, their ideological, aesthetic, genre originality and the connection of these works with the cultural heritage of the Turkic peoples. This source from N. Isanbet's archive has been introduced into scientific circulation for the first time. This is the novelty of the work. The dastan and the Bashkir song "Kongyr Boga" are studied in the context of the relationship of song, music and oral folk art of the Turkic peoples. The study proves that the origin of these sources is based on the ancient people's ideas about the world and the surrounding phenomena, on mythology, legends and epics. N. Isanbet highlights both to the depth of the semantics and the emotional power inherent in the song "Kongyr Boga", and the dialectical relationship of its content and form, the features of the song performance. The article reveals the national peculiarities of the ways these texts sound and focuses on the nobility of the people's patriotic feelings, which found their embodiment in these ancient works of folklore.

**Key words**: song, melody, Turkic peoples, cultural interrelations, "Kongyr Boga", epic, legend, patriotic feelings

---

[1] The article is stored in the personal archive of Naki Isanbet. In the original, the article is called "Kongyr Boga" (devoted to the manifestation of friendship between peoples in the music of kindred peoples)". The design of the article was brought into accordance with the journal format by the editor of the magazine "Tatarica" T. Sh. Gilazov. [1] The author of the scientific comments, based on the scientific works of N. Isanbet and other scholars, is M. M. Khabutdinova, the editor of the journal "Tatarica".

## Introduction

Despite the fact that we have some official factual information about historical and current relations and mutual influences existing in fraternal Turkic peoples' languages and literatures, about our meetings and campaigns, unfortunately, no such works in the area of music and song can be found.

However, in real life such relationships exist and develop independently. For example, Azerbaijani melodies, which have come through the stage musical comedy, and songs written under their influence in our country (works by Fattah Latypov. - N. I.), as well as some folklore Kazakh melodies sung in our country before. Let's remember "Өмеркән" ("Umerken" –"Life"). The songs "Уналты кыз Нәгыймәй, Фатыймәй" ("Unalty kyz Nageimei, Fatyimei" – "Sixteen Girls Nageimei, Fatyimei") and "Әниемә" ("Enieme" – "To Mum") by Shamshi Kaldayakov are listened to and sung by our people. In terms of folk melodies, we have long been closely connected with the Bashkirs. Singing and dancing to the tunes, ranging from the former Bashkir dance melodies "Ашказар" ("Ashkazar"), "Зөлхиҗә" ("Zulhiya") to "Баек" ("Bayek"), "Гөлзәбирә" ("Gulzabira") and "Карабай" ("Karabay") testifies to this. This creative friendship, this mutual spiritual cooperation, the exchange of cultural treasures has been maintained not due to any official decrees or orders, but due to the people's own desire and due to their spiritual call. Therefore, history holds no information that these relations were initiated by some heads of the office, who would have done this, wanting to rise to high eminence in culture.

## Materials and research methods

This scientific research is based on the epic "Kongyr Boga", the Bashkir melody "Kongyr Boga" and ancient legends. The work uses traditional methods of description, comparative-historical methods and the work on scientific sources, their analysis and generalization.

## Discussion

Today, I will dwell on one of the tunes from the radio broadcast. Radio. A weekend concert. The Bashkir chant "Kongyr boga" is being performed. It is performed by the Tatar Philharmonic Choir [2].

The the song of "Kongyr boga"[2] has the words– "hau-hau" ... This is a strange phrase that sounds so beautiful and harmonious. But what it means and why we feel moved and impressed. Many of us don't even seem to understand what it is...

One of the legends tells us about it in this way[3]:

Allegedly, in the Bashkir tribe of the Urals, one cow was pregnant. When the owner of the cow married her daughter off world away from home, she gave the cow along as her dowry, sending her somewhere far, far away from the Urals. A calf was born there, which became the "Kongyr boga". But, according to what people say, the feeling, called longing for the land of the ancestors, is such a deep emotion that it is absorbed into one's blood and is passed from generation to generation. Even a bull-calf, born in a foreign land, as this old song tells us, could not get used to the foreign land, and one day, missing his homeland, he went towards

[2] "Kongyr boga" is a brown bull, a young brown bull. – *Note by N. Isanbet.*

[3] The personal archive of N. Isanbet has a certificate of the Bashkir complex expedition of the USSR Academy of Sciences in 1928 (See: [3, pp. 109–114, 320–395]. In the 1910–1930s, the teacher-scientist, having traveled along and across Bashkortostan, put a lot of effort into collecting Tatar and Bashkir folk art and folk epics (See: [3, pp. 109–114, 320–395]. During the expedition, N. Isanbet recorded three versions of the Bashkir epic "Idukej menan Moradum" from the old people, supplementing them with scientific comments and an introductory article, later he handed it over to the Scientific Society. At the beginning of 1930, the scholar prepared a collection of works, it passed a scientific examination and was submitted for publication to the Bashkir book publishing house [4, pp. 7–10]. Because of Zhidegan, the book was never published. Ten years later, a part of the work – the text "Idukej menan Moradum" – was translated by M. Sundyul into the Tatar language and published in the issues of April 28, 29 of the newspaper "Commune" [5]. At the meeting of the Union of Writers of the USSR and at the regional party conference, the epic "Idukej menan Moradum" was declared "a brilliant work of the Bashkir people" [6]. For the first time, N. Isanbet mentioned "Kongyr boga" in the collection of works "Idukej menan Moradum": "Kongyr boga –a bull". In the notes to the work, the scholar writes that in the Bashkir legend, the bull is the image of the holy cattle, bringing happiness and prosperity, that the Kongyr's path along the Ural ridges connects east with west, north with south. – *Note by M. Khabutdinova.*

the Urals[4], trying to find the right direction ... Thus, the melody "Kongyr boga" was born[5].

Of course, this legend is associated with tribalism, nomadic animal husbandry and the fatherland. Its melody and music today sounds interesting, strange to us, but at the same time, it is native and beautiful.

Okay, let the word "kongyr boga" mean "a brown bull". But what does "hau-hau-hau" mean? Dogs' sounds? Or is the bull in the homeland met by barking dogs? Is it driven back from its parental home to be exiled?

Of course, "hau-hau ..." is not a dog barking, but simply an expression of tenderness for bulls and cows.

As, for example, M. Gafuri's work has the affectionate appeal "шул вакыт бер яшь килен 'һәй-һәү' диеп сыерын сава" ("shul vakyt ber yash kilen 'hei-heu' dip syeryn sava" – "at this time a young woman is milking a cow, addressing her 'hey-hey'").

And when these "hau-hau" lines are sung, perhaps they should be sung not like a dogs' bark, but rather like a melody of homesickness by a tormented mythical or totemic bull, and the chorus should greet and caress "kongyr boga", addressing it affectionately "hau-hau".

What I can think of is a similar tune of the Siberian Tatars, in Tyumen and Tobolsk [9]. This is also mentioned in the inscriptions preserved from the 15$^{th}$-16$^{th}$ centuries. At this point, I am not going to discuss them yet. Nevertheless, it must be said that the melody "Ilche baga", recorded in the 40-s from the Tatars living on the banks of the Irtysh, the melody that was spread in Kazan, is dedicated to the same topic. The name of the song was modified from the phrase "Ilche boga", and here boga also means a bull. This is one of the light, joyful melodies. Now, it seems, it has not preserved the old lyrics, and modern songs are sung to the old melody. Nevertheless, the old interjections are preserved in the choruses. If you listen carefully to the words:

Һәү-һилләү, һилләү-ләү (heu-hilleu, hilley-leu)

Һәү-һилләү, һилләү-ләү (heu-hilleu, hilley-leu).

you can understand that they correlate with "hau-hau". However, judging by the joyful melody and comparing it with the Bashkir "Kongyr boga", the legend of this "Kongyr boga" was not only ancient totemism. It was a kind of a solemn ceremony among the Turkic peoples and it was carried out as a theatrical ceremony. When people saw that the "Kongyr boga" was returning, they did not know what to do, they cried and laughed ...

- Stop it, you will say, what is it? As if they had never seen bulls before, why would the whole village be surprised! Look, we have a dozen such "boga" (bulls) sent to a meat processing plant. And no one cares. Aren't there many bulls that have gone lost and astray? What difference does it make whether they come back or not? We're talking about a man now! He must be sung about, but not the bull! Look, they greeted him like a hero, crying with joy and laughing! One might think how

[4] The "Bashkir Encyclopedia" contains interesting scientific material about the history of this song: "KONGYR-BOGA" is a memorial of the Bashkir verbal art, the epic. It was first recorded by R. G. Ignatiev and published in 1865 in the "Orenburg Provincial Newspapepr". Variants of the epic of the same name were recorded by M. A. Burnagolov, K. Margan, G. Salyam, R. Shakur. "Kongyr-boga" is included in the cycle of Bashkir legends about animals, such as Akhkak yurga and Kara yurga. The work reflects the Bashkirs' ancient ideas about sacred animals that bring happiness and prosperity. The main character of the epic gets married and moves far from her home. She takes a brown cow as her dowry. After many years the calf of this cow, following the "Kongyr boga", leaves the haven of nomadic peoples. The owner of the animals, addressing them with a song, follows them. The animals lead her to her home. The road, along which she goes and returns home, is popularly called "the road of Kongyr boga". More than 10 versions of the epic from the territories of the Republic of Bashkortostan, Orenburg and Samara regions are stored in the Scientific Archive of the UFSIN RAS [7, p.605]

[5] The "Bashkir Encyclopedia" provides interesting information about the Bashkir folk song of the same name: "KONGYR BOGA" ("Kongyr boga" – "A young bull calf"), a Bashkir folk song with a calm melody. In 1907, M. Burangolov made the first recording from Khasan Burangolov in the village of Verkhnyaya Ilyasa, the Samara district (now the Krasnogvardeisky district, the Orenburg region). In the collection "Bashkir Folk Songs" (1935), it was published by S. Gabashi. Kh. Akhmetov and L. Lebedinsky worked on subsequent publications. The song is of epic character. In search of the lost brown bull, the heroine composes a song on the way. The melody is based on pentatonic sounds, the size of the verse (beginning) is characterized by a soft, 3-beat, smooth style; the refrain has a structure, approaching the short melody of a 2-beat rhythm, and is characterized by a smooth movement, and abundant repetition of the syllable "hau" as an appeal to the animal. One of the performers was H. Almukhametov. "Kongyr Boga" for voice and piano was arranged by Akhmetov, A. Klyucharev arranged it for choral performance and symphony orchestra [8, p. 605]

ignorant these ancient people were. Or really stupid.

And yet I'm not surprised. Modern people, who are "born with a completed seventh grade education", who study algebra at the age of four and distribute all the benefits according to their scientific categories, they do not understand the feeling of joy for the bull that has returned to its homeland. It's not easy to understand. If only we had not turned into a prudent person or a modern electronic computer, if our imagination could be at least a little ... more vivid, in order for us to comprehend this situation. We need to break from the present, jump back in time and imagine ourselves as a person living at that time.

It's not an easy thing to do. How far can this jump go? I don't know. But let's try anyway.

In the days when legends existed, there was no "connection between the countryside and the city", perhaps even these words did not exist, but there were some special connections between man and nature, people closely interacted with the nature around them, with its vegetation and animals. They drank from natural rivers and springs, scooping water from ditches or leaning forward to get it like animals do, they breathed the same air. Why not breathe it! Since they brought home newborn curly lambs and slept hugging them! And the calf that was nearby and was looked after. It came up and chewed on the hem of its mistress's dress while she was kneading dough. It cannot be said that they smelled fine and ignorance is generally worth keeping silent about, but there was one thing: the air was clean and fresh, not spoiled by the smell of gasoline or car fumes, there were no shops with vodka everywhere. If you wanted to breathe, there was clean air, if you wanted to drink, there were pure natural waters and a boiling samovar, and tea brewed with the same water on the table from dawn till dusk.

This is already a thing of the past... People lived their simple lives, in direct dependence on the nature around them, on the strength of bulls and horses, on meat, milk, koumiss, fats and the skin of these animals. I don't know if people harnessed horses then or vice versa. Yet the boys, although they did not harness cows, they rode horses, and adults rode them and harnessed them …. People lived in harmony with these animals, which provided them with milk, meat, which helped to cultivate the land and grow and reap the harvest; yes, there were disagreements and reconciliations between them, they tried to understand each other, explain themselves, wanting to know or share their problems, they sang, whistled or whispered. Apparently, as Tukay said, chickens did not cackle, but sang then. And if suddenly lightning happened to strike, rivers flooded, a fire broke out, people did not run to send telegrams or make calls, but turned to nature. If there was a total solar eclipse, people and their animals wept bitterly remembering all their sins and prayed. When the eclipse slowly began to pass away, they rejoiced like children and congratulate each other, believing that their prayers had been accepted.

After the above presented reflections, let's return to the "Kongyr Boga" again, and the same thing is found here. Is this a joke? Look, "the son of a bull – a young calf", which was considered to be our ancestor, was devoid of his father's home! (And let's not forget that the bull, possibly the ancestor for these ancient people, was their totem? N. Isanbet)

Still in the womb, it was aware of being in a foreign land and being born there. And then our bull-calf got homesick and, unable to stand it, furiously pounded the ground with its hooves, sniffing, tears flowing from its eyes ... And off it went to look for its homeland, its parental home. It couldn't speak, but its soul could feel, and despite all the sufferings, it returned! It found its father's house, it came back[6]. No, no, this is not a simple case, it's an amazing one. Even today, hearing this magical story, the audience rejoices. At that time, everyone was in a hurry to look at this extraordinary bull, people ran to the square to watch this magical sight. Everyone believed it to be an extraordinary event. All singers and musicians made it into a song, its biography into a dastan, describing the difficult fate of the bull, who managed to break its chains, get free from its shackles and return to its homeland. The people who listened to the song with bated breath were surprised and wept.

And the following words answer the question of a man, living in those times:

- No, abzy, it is the same "Konyr boga" who climbed to the top of the mountain and, feeling home in its heart, in its guts, it searched for the house along the roads that no man had set foot on, paving the way.

It was impossible to celebrate the return of this bull without performing solemn, totemistic songs,

[6] In the Urals, the Bashkirs point to a long road to prove their words, adding that these are the traces of the "Kongyr God". The long road, they say, did not run anywhere across the river, so that the bull did not wet its hooves anywhere ... – *Note by N. Isanbet.*

dastans and making a sacrifice. After all the festivities, people sang such light, happy, short songs as “Ilche baga”. And, probably, they danced to these ditties. In those times, song, melody, dance were inseparable from each other and such events could not be imagined without musical rites. It was probably just the case that time too...

Emotion is a catching thing, but one should not think that everyone perceived this “kongyr boga”, who had lost its herd, in the same way. People will be people. Despite the fact that people are collective creatures, they evaluate everything in their own way, based on their own experiences.

The ancestor of the ancient Turks is said to be “Ugyz Khan” and their progenitor was a bull / totem. What would this mythical ancient “Kongyr boga”, coming in search of his father’s house, see now? Of course, the bull would see that he returned in search of a totemic feeling. People stop and stare seeing in this bull the personification of this paternal spirit, this love for the motherland, so the bull seems to be a holy phenomenon. Other people compare “Kongyr boga” with the son of a great khan who was killed during one of the wars, and his wife, who had his child in the womb, gave birth to a son in foreign lands. As you can see, everyone lives in their own world, this is their own world, the universe of their own life, of their own historical society and the universe of the association of legends. Even if you find this vast land, you will not be able to enter it with any archaeological excavations. You will not be able to advance further on, you will be lucky if you scoop up a shovel of that earth and hear the “Kongyr boga”. Apparently, ancient man lived in his own world, incomprehensible to us; he sparked ideas and gained experiences in his own way. That’s exactly why people experience different emotions when they see “Kongyr boga”. That is why dombrists praise it, because it was not afraid of anything, neither death, nor people, it came to the land of his origin and found his treasure. That is why some people cry, hugging it, while old women, having seen a lot, lament and, in order not to jinx it, hang silk fabric and silver badges around its neck. Watching all this, the bull becomes the hero of the dastan. And the whole square, congratulating him, sing “Kongyr boga” “hau-hau!...”

## Results

Thus, I believe that this old, beautiful melody “Kongyr boga”, apparently, is a kind of spontaneous manifestation of warm feelings for the motherland. It should not be forgotten, despite the fact that the song is a melody, ancient people’s folklore, which is spontaneous and improvisational, everyone experiences their own specific feelings. Here is this melody - in this song, in this legend and in the rite “Kongyr boga”. What brings people together, what makes them sing, of course, is the feeling of love for the motherland and the longing for it, which is characteristic of both people and animals. This is the secret of the song’s strong impact.

In the Urals, the songs, associated with the legend of this bull, were called “Коңгыр бога” (“Kongyr boga”), in the Bashkir language – “Куңгыр буга” (“Kungyr buga”) and “Ҡуңыр буға” (“Kunyr boga”), “Коңор бого” (“Konor boga”); in the Irtysh region it was “Илче бага” (“Ilche baga”), in the Kama region, perhaps, the name was “Ала буга” (“Alabuga”) or some other name was used. In the Volga-Urals, the name “Бугырслан” /Буга арыслан?/ (“Bugyrslan” /Buga aryslan?/) or “Богавы” (“Bogava”) is used quite a lot. If we delve into history, we may understand if these names have survived from the time when herds of elks walked freely on this land, because elks were called “bugu”. As for the moose, they were considered to be holy animals, they could not be touched, and the people who killed or hunted them were exposed throughout the country and cursed in bayts.

## Conclusion

Obviously, some verses, songs and melodies have been preserved in “Kongyr-boga”, but this ancient dastan has not survived. Listening to this amazing melody, it is clear that neither the listeners nor the performers understand what it is about, in what way *hau-hau* is pronounced: is it a dog barking or some sort of affectionate address? Of course, a song can be sung without understanding its meaning, but only by singing words. However, if the song were performed, based on the legend and the history of the melody, if the song had words, it would sound much better and be more impressive. If skilled directors and conductors could use these plots, they would enrich traditional melodies with rich performances, interesting games, dances or other details. A modern choir, choreography, bull-horned masks and folk amateur art can provide every opportunity to describe such songs against the backdrop of a solemn square and create a song performance.

**References**

1. Isanbet, N. (1968). *“Kongyr boga”* [The Brown Bull]. Iz lichnogo arkhiva N. Isanbet. Rukopis'. Napechatan na mashinke, 11 p. (In Russian)
2. *“Kongyr boga”* (1968) [The Brown Bull]. Iz fonda radio Tatarstan. Dirizher i khormeister: Dzhavid Kotdusov. 3 min. 24 sek. (In Russian)
3. *Naki Isanbet* (2021) [Naki Isanbet]. Sostavitel' M. M. Khabutdinova. 736 p. Kazan', fond “Җyen (Sbornik)” knizhn. izd. (In Russian)
4. *Idukai i Muradym. Istoricheskii kubair* (1994) [Indukai and Muradym. A Historical Kubair]. 352 p. Ufa, Bashkortostan “Kitap (Kniga)” knizhn. izd. (In Russian)
5. *Idukəi həm Moradum* (1940) [Indukai and Muradym]. Kommuna. No. 78 (1477). 28 aprel'; 79 (1478) 29 aprel'. (In Tatar)
6. *Izdatel'stvo, literatura, narodnoe tvorchestvo* (1940) [Publishing, Literature, Folk Art]. Matbugat, ədəbiyat, khalyk iҗaty. VKP(b) ølkə komitetynyң sekretare iptəsh Anoshinnyң Bashkortstan partiya oeshmasynyң XX ølkə konferentsiyasendə søiləgən dokladynnan. Oktyabr'. No. 5, 9 p. (In Tatar)
7. Shakurov, R. Z. (2007). *“Kunyr buga”. Bashkirskaya ehntsiklopediya* [The Brown Bull. Bashkir Encyclopedia]. T. 3, p. 605. Ufa, Nauchnoe izd-vo “Bashkirskaya ehntsiklopediya”. (In Russian)
8. Khamitova, G. Ch. (2007). *“Kunyr buga” Bashkirskaya ehntsiklopediya* [The Brown Bull. Bashkir Encyclopedia]. T. 3, p. 605. Ufa, Nauchnoe izd-vo “Bashkirskaya ehntsiklopediya”. (In Russian)
9. Batyrshin, R. R. (2010). *Sibirskie tatary. Tatarskaya ehntsiklopediya* [Siberian Tatars. Tatar Encyclopedia]. T. 5, pp. 313–315. Kazan', Institut Tatarskoi ehntsiklopedii AN RT. (In Russian)

---

# «КОҢГЫР БОГА» КӨЕ: ТАРИХИ ТАМЫРЛАРЫ ҺӘМ ПОЭТИКАСЫ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР МӘДӘНИЯТЕ КОНТЕКСТЫНДА[1]

**Нәкый Исәнбәт**,
Казан,
mileuscha@mail.ru.

«Коңгыр бога» дастаны һәм аның белән тыгыз бәйләнештә туган «Коңгыр бога» башкорт көе мәкаләнең бәяләү объекты булып тора. Бу ядкәрләрнең иҗат ителү тарихы, идея-эстетик, жанр үзенчәлекләре һәм мәдәни мирас белән бәйләнеше мәсьәләләре фәнни хезмәтнең тикшерү предметын билгели. Әлеге рухи хәзинәләр беренчеләрдән булып фәнни әйләнешкә кертелә һәм ул мәкаләнең фәнни яңалыгы буларак каралырга хаклы. «Коңгыр бога» дастаны һәм «Коңгыр бога» башкорт көе төрки халыкларның җыр, музыка һәм халык авыз иҗаты бәйләнешләре контекстында тикшерелә. Аларның барлыкка килү тарихы борынгы кешеләрнең дөнья, андагы күренешләр турындагы күзаллауларына, мифологиягә, риваятьләргә, эпосларга нигезләнеп шәрехләнә. «Коңгыр бога» җырына салынган мәгънәнең тирәнлеге, хисси-эмоциональ көче бәяләнү белән беррәттән, Н. Исәнбәт аның төзелешенә һәм башкарылу осталыгы проблемаларына да игътибарын юнәлтә. Җырның башкарылу сәнгате эчтәлек һәм форма белән диалектик бәйләнештә каралып, аны җырлау үзенчәлекләре дә мәкаләнең шәрехләү предметы булып тора. Автор «Коңгыр бога» җыры аһәңенең, моңының халыкларның борынгы табигый, изге ватанчылык хисе, туган илне сагыну, җирсенү хисе белән тыгыз бәйләнешен ассызыклый.

**Төп төшенчәләр**: җыр, көй, төрки халыклар, мәдәни бәйләнешләр, «Коңгыр бога», эпос, легенда, ватанчылык хисе

---

[1] Мәкаләнең оригиналдагы исеме «,,Коңгыр бога“ (Музыкабызда тугандаш халыклар ара дуслык мөнәсәбәте уңае белән)» дип атала. Кульязма Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивында саклана [1]. Фәнни язманың төзелеше «Tatarica» журналының «Әдәбият» бүлеге редакторы Т.Ш. Гыйлаҗев тарафыннан журнал таләпләренә туры китереп үзгәртелде. Фәнни комментарийларны Н. Исәнбәтнең һәм башка галимнәр фәнни хезмәтләреннән алып тулыландыручы – «Tatarica» журналы редакторы М.М. Хәбетдинова.

### Кереш

Тугандаш төрки халыклар белән тел һәм әдәбият буенча тарихи һәм бүгенге мөнәсәбәтләр йә йогынтылар хакында, ара-тирә очрашулар яки кампанияләр уздырылганда, рәсми һәм кәҗүнниерәк төстә булса да, белешмәләр бирешү кебек аз-маз эшләребез күренсә дә, ләкин музыка һәм җыр-көй тармагында моңарчы күзгә чалынган андый хезмәтләр дә булмады шикелле.

Әмма тормышта мондый мөнәсәбәтләр бар һәм алар үзлегеннән дәвам итә. Мәсәлән, азәрбайҗан сәхнә – музкомедиясе аша кергән җыр-көйләр һәм шул йогынты белән бездә дә язылган көйләр (Фәттах Латыйпов әсәрләре. – *Н.И.*), фольклордан элек бездә кайбер казакъ көйләре җырланды. Әйтик «Өмеркән». Хәзер дә «Уналты кыз Нәгыймәй, Фатыймәй», яки Шәмши Калдаяковның «Әниемә» дигән көе дә халкыбызда бик яратып тыңлана һәм җырлана. Халык көйләре ягыннан караганда, башкортлар белән без элек-электән тыгыз бәйләнештә. Башкортның элекке «Ашказар», «Зөлхиҗә»ләреннән алып «Баек», «Гөлзәбирә», «Карабай» кебек бию көйләренә кадәр татарда җырланып, уйналып йөрүе шундыйлардан. Бу иҗади дуслык, бу үзара күңел хезмәттәшлеге, бу рухи хәзинәләр белән уртаклашулар нинди дә булса рәсми чаралар, боерыклар буенча түгел, бәлки халыкның үз зәвык, һәм үз татым әйдәве белән үзлегеннән эшләнгән. Шунлыктан бер канцелярия башлыгының да бу без кушкан буенча эшләнде дип үзенә шуның белән культурада беренче урынны даулаганы тарихта күренми.

### Фәнни хезмәтнең материалы һәм методлары

«Коңгыр бога» эпосы, башкорт көе «Коңгыр бога», борынгы риваятьләр, легендалар фәнни мәкаләнең өйрәнү материалы һәм чыганаклары булып тора. Хезмәттә тасвирлама, чагыштырма, чагыштырма-тарихи, фәнни чыганаклар белән эшләү, анализ һәм гомумиләштерү традицион методлары кулланылды.

### Фикер алышу

Мин бүген эфирдан тапшырылган көйләрдән берсенә тукталам. Радио. Ял концерты. Менә башкорт көе «Коңгыр бога» башкарыла. Аны Татар филармония хоры башкара [2].

Җырның кушымтасы безгә «Коңгыр бога»[1] «һау-һау»... дип көйләп кабатлап тора. Бу шундый матур, көйләнеп яңгырап торган гаҗәп бер сәер фраза. Әмма ләкин ни дигән сүз, нәрсә ул сизенәбез кебек, тәэсирләнәбез дә. Алай булса да мәгънәсе, ни икәнен күпләребез аңлап та җиткермибез кебек...

Легендаларның берсе безгә бу хакта шулай сөйли[2]:

Имештер, борын Уралда яшәгән башкорт ыруындагы бер сыер буаз була. Йорт хуҗасы үзенең кызын каядыр чик якка кияүгә биреп озатканда, кыз малы итеп шул буаз сыерны да биреп, аны Уралдан каядыр ерак-ерак чит җиргә озаткан була. Менә шуннан бу сыер карынында киткән бозау анда «Коңгыр бога» булып туган. Әмма халык уенча, төп ватаның булган ата-баба җирен сагыну дигән нәрсә табигатьтә шундый көчле һәм канга сеңешкән бер тирән хис булмак кирәк ки, ул хәтта нәселдән-нәселгә күчә ала. Шуның белән бу

---

[1] «Коңгыр бога» – коңгырт үгез, коңгырт төстәге яшь үгез дигән сүз. (Монда – башмак үгез.). – *Н. Исәнбәт искәрмәсе*.

[2] Н. Исәнбәтнең шәхси архивында 1928 елдагы СССР Фәннәр Академиясенең Башкорт комплекслы экспедициясенең таныклыгы саклана (Кара: [3, б. 109–114, 320–395]). 1910 – 1930 елларда укытучы-галим җәяүләп, Башкортстанны аркылыга-буйга йөреп, татар һәм башкорт халык иҗатын һәм халык эпосларын җыйнау эшенә бик күп көч сала (Кара: [3, б. 109–114, 320–395]). Экспедиция вакытында Н. Исәнбәт «Идүкәй менән Морадым» башкорт эпосының 3 вариантын картлардан язып алган һәм аларны фәнни комментарийлар һәм кереш мәкалә белән Фәнни җәмгыятькә тапшырган. 1930 елның башында галим, җыйнама төзеп, фәнни экспертиза аша үткәреп, үз хезмәтен Башкорт китап нәшриятына биргән [4, б. 7–10]. «Җидегән» эше аркасында китап басылмыйча калган. 10 ел узгач, хезмәтнең бер өлеше – «Идүкәй менән Морадым» тексты – М. Сөндекле тарафыннан татарчага тәрҗемә ителеп, «Коммуна» газетасының 28, 29 апрель саннарында басылып чыккан [5]. СССР Язучылар союзы секциясендә һәм өлкә партия конференциясендә «Идүкәй менән Морадым» эпосы «Башкорт халкының гениаль иҗаты» дип игълан ителә [6]. Н. Исәнбәт тарафыннан беренче тапкыр «Коңгыр бога» «Идүкәй менән Морадым» җыйнамасында телгә алына: «Конгыр бога бозау». Галим үзенең искәрмәсендә аның башкорт риваятендә бәхет һәм муллык китерә торган изге мал образын аңлатуын, Конгыр бога юлының Уралтау сыртлары буенча көнчыгыш белән көнбатышны, төньяк белән көньякны тоташтырган бик борынгы юл булуын әйтеп китә. – *М. Хәбетдинова искәрмәсе*.

борынгы җыр-көйдән күренүенчә, хәтта шушы бер хайван баласы булып читтә туган бу үгез-бога да, ят җиргә табигате ияләшә алмыйча, көннәрдән бер көнне үз ватанын җирсенеп, башын бер якка алып, үкерә-үкерә аны эзләп, ата йорты Уралга әйләнеп кайта[3]... Менә шуннан «Коңгыр бога» көе туа[4].

Сүз дә юк, бу легенда кавемчелеккә, күчмә терлекчелеккә һәм ватанчылыкка бәйләнешле. Аның көе дә җыры шикелле, бүген безгә бик сәер, кызыклы, шуның белән бергә, үз һәм матур булып ишетелә.

Ярый, «Коңгыр бога» дигәне коңгырт үгез дигән сүз булсын. Әмма бу «һау-һау-һау!» – дигәне ни? Эт өргән тавышлармы? Йә булмаса, әллә ул үгезне төп туган илендә шулай этләр амалап өреп каршы алалармы? Аны ата йортыннан кире куалар, сөрәләрме?

Билгеле, «һау-һау...»лар монда эт өрүе түгел, бәлки үгезләрне, сыерларны яратып, әйтеп, эндәшү ымлыгы гына.

Әйтик, М. Гафуриның «шул вакыт бер яшь килен, "һәй-һәү" диеп, сыерын сава» дигәндәге яратып эндәшү шикелле.

Шулай булгач, ул сүзне җырлаганда да, «һау-һау!» дип, «туп-турыдан туп пошел» дигәндәй, эт өргән тавышлар белен түгел, киресенчә, аны үзенең төп туган илен сагынып, эзләп кайтып килгән бу мифик яки тотем үгезнең үз җир-суын, җирсенү авазлары итеп яңгыратырга яки, җырын җырлаган кешеләр ул «Коңгыр бога»ны үз итеп чакырып, «һәү-һәү» яратып, хуплап, хорда да аңа җылы тавышлар белән «үкереп» эндәшеп каршы алырга тиеш дип беләм.

Искә төшкәннән шуңа охшашлырак сыбыр[5] татарларында, Төмән-Тубылда да бик мәшһүр [9]. Бу хакта XV-XVI йөзләрдән үк калма язуларда да очрала. Бу урында әле аларына тукталмыйм. Алай да булса, безнең бу заманда әле 40 нчы елларда гына Иртыш буе татарларыннан ишетеп язып алынып, Казанда да таралган «Илче бага» көе дә шулар ишеннән булуын әйтергә кирәк. Ул төптә «Илче бога» сүзеннән үзгәргән, ягъни монда да бога – үгез турында әйтелә. Бу үзе бер җиңел, шатлыклы көйләрдән. Хәзер аның элекке җырлары да калмаган ахыры. Бары тик көенә теләсә нинди хәзерге җырларны әйтеп җырлый бирәләр. Алай да кушымтасында иске ымлыклар калган. Андагы:

Һәү-һилләү, һилләү-ләү
Һәү-һилләү, һилләү-ләү.

дигән сүзләренә караганда, ул да баягы «һәү-һәү»ләр белән бер иштәнрәк булуы аңлашыла. Әмма инде көйнең шатлыклы булуына караганда, аны башкорт «Коңгыр бога»сы белән дә бер төр типта куеп чагыштыргач, бу «Коңгыр бога» легендасы

---

[3] «Башкорт энциклопедиясе»ндә бу көй тарихы турында кызык фәнни материал тупланган: «**КОҢГЫР-БОГА»** башкорт сүз сәнгатенең истәлеге, эпос. Тезмә һәм чәчмә формада яши. Р.Г. Игнатьев тарафыннан беренче тапкыр язып алына һәм 1865 елда «Оренбург губерна ведомост»енда басыла. Эпосның бер исем астындагы вариантларын М.А. Бурнаголов, К. Мәргән, Г. Саләм, Р. Шәкүрләр язып алган. «Коңгыр бога» башкорт риваятьләренең Ахкак юрга, Кара юрга кебек хайваннар турындагы циклына керә. Әсәрдә башкортларның бәхет һәм муллык китерә торган изге хайваннар турындагы борынгы күзаллаулары чагылыш тапкан. Эпос героинясы кияүгә чыгып, үз туган йортыннан еракка китә. Бирнәгә ул коба (коңгырт) сыер ала. Берничә ел үткәч, бу сыерның бозавы Конгыр богага (Коба үгезгә. – *Т.Г.*) ияреп, күчмә халыклар тукталган урынны ташлап китә. Хуҗабикә, җыр белән эндәшеп, алар эзеннән бара (Кара: «Конгыр бога»). Хайваннар аны ата-ана йортына китерәләр. Героиня туган йортка килгән һәм аннан кире киткән юл халык телендә «Коңгыр бога юлы» дип йөртелә башлый. РФА УФҮнең Фәнни архивында эпосның Башкортстан Республикасы, Оренбург, Самара өлкәләре территорияләреннән язып алынган 10нан артык варианты саклана» [7, с. 605] (тәрҗемә. – *Т.Г.*)

[4]. «Башкорт энциклопедиясе»ндә шул исемдәге башкорт халык җыры турында кызык мәгълүмат бирелә: «**КОҢГЫР БОГА»** («Куңыр буга» — «Коба яшь үгез бозау»), башкорт халык җыры, салмак көй. 1907 елда М.А. Буранголов Самара губернасы Бозаулык өязе Югары Ильяс авылында (хәзерге Оренбург өлкәсе Кызыл гвардия районы) Хәсән Буранголовтан беренче тапкыр язып ала. «Башкорт халк йырлары» («Башкорт халык җырлары, 1935) җыентыгында С. Габәши язмасында басыла. Шуннан соңгы язмаларны Х.Ф. Әхмәтов, Л.Г. Лебединский эшли. Җыр эпик характерда. Поэтик текст «Коңгыр бога» эпосының фрагменты булып тора: югалган коңгыр боганы эзләргә чыккан героиня юлда җыр иҗат итә. Көй пентатоник авазларга нигезләнә, куплетның (башлам) үлчәме хикәяли торган 3 өлешле, салмак; структурасы белән 2 өлешле кыска көйгә якынайган кушымта салмак хәрәкәткә корылган, хайванга эндәшүне белдергән «һәү» иҗегенең мул кабатлануы белән характерлана. Башкаручыларның берсе Х.С. Әлмөхәммәтов. «Коңгыр бога»ны тавыш һәм фортепиано өчен Әхмәтов, ә хор һәм симфоник оркестр өчен А.С. Ключарев эшкәртә [8, с. 605] (тәрҗемә. – *Т.Г.*).

[5] Сыбыр татарларында – себер татарларында – *Т.Г.*

кайчандыр бик борынгы тотемизмнан калма, коры бер җыр гына булып калмый күрәсең. Ул төрки халыкларда үзенә бер тантаналы йола булырга һәм ул йола мәйдан театраль тамашалы итеп уздырылган булырга тиеш. Кешеләр анда «Коңгыр бога»ның кайтуын күргәч, куанычларыннан нишләргә белми, елашканнар да, көлешкәннәр дә...

- Тукта, диярсез, монысы нәрсә инде тагын? Үгез күргәннәре юкмы, бөтен авыллары белән купмасалар! Шуның өчен бу кадәр тамаша? Әнә, бездә аның ише «бога»ларны дистәсе белән бастырып, шәһәр аша ит комбинатына суемга алып китеп торалар. Көн дә күреп торабыз, беркемнең дә исе китми. Андый иленйортын югалткан, адашкан үгезләр булмыймыни? Әйләнеп кайтса ни дә, кайтмаса ни? Хәзер кеше дибез бит инде! Аны җырларга кирәк, ә болар – үгез! Әле үзләре шуңа шаккатып, әллә нинди бер зур каһарман кайткан кебек каршылап, куанычларыннан җылашып, көлешеп нишләргә белмәүләрен кара! Бер уйласаң, бигрәк тә сәер, кара надан булган да инде бу борынгы кешеләр. Әллә инде бөтенләй дә җүләр сымакмы шунда.

Шулай дисәгез дә, бер дә гаҗәпләнмим. Хәзер инде безнең бу заманда, «туганда ук җидееллыкны бетереп туган», дүрт яшендә алгебра укыган, үзенең фәнни балигъ булып җиткәнче үк, һәр нәрсәгә үзенең фәнни-гыйльми категорияләре печатен сугып, паспортизация ясап бетергән бүгенге кеше өчен борынгыларның шушылай илгә кайткан бер башмак үгез өчен мәйдан кубулары чынлап та аңлашылып та җитмәс. Моны төшенү җиңел эш түгел. Әгәр дә без хәзер үзебездә шакылдап торган коры акыл кешесенә яки заманча электр - исәп машинасына әйләнеп калмаган булсак, әгәр дә әле хыял дигән үз «машина»быз телевизор кадәр үк булмаса да, бераз гына эшли торган булса, ... безгә хәзер бу хәлне аңлау өчен, күрәсең, бу урында бу заманнан кинәт кенә берничә гасыр артка сикереп кайтып төшәргә, үзебезне андагы кешеләрнең берсе итеп уйлап карарга кирәк.

Җиңел эш түгел. Күпме сикереп булыр. Белмим. Алай да тәвәккәлләп карыйк.

Әле ул борынгы легендар заманнарда «авыл белән шәһәр арасында элемтә» дигән нәрсә, хәтта ул сүз үзе дә булмаган, алай да кеше белән табигать арасында ниндидер үзенә бер төрле элемтә булган, кешеләр үз тирәләрен чолгаган табигать, андагы үсемлек, хайваннар белән ничектер, бер-берләренә якын аралашып яшәгәннәр. Алар анда табигый аккан елгачишмәләрдән агым сулардан сулар алып яки шул хайваннар кебек үк аларга иелеп ятып эчкәннәр, алар белән бер рәттән бер үк һаваны сулаганнар. Ничек суламассың. Кышын кечкенә бөдрә бәрән, бәтиләрне кочаклап, өйгә алып күтәреп кертеп кундыргач! Анда тагы әле шунда булган, торган юаш бозау да буш калмаган. Хуҗа хатыны камыр баскан арада тыныч кына арттан аның итәген чәйнәгән. Төрле тәмле-тәмсез исләр анда да чыкмаган түгел, ә инде андагы наданлык-томаналыкны әйткән дә юк, тик бер ягы шул: урамга чыксаң, һавада балта элсәң төшмәслек яшел бензин газы, алдыңда да агымсу урынына будка-будка аракы тормаган. Сулыйм дисәң һавасы, эчим дисәң табигый чын сулар җитәрлек, бик теләсәң, әнә пар бөркеп торган самавыр белән шул суда пешерелгән кайнар чәй дә иртәдән кичкә кадәр өзелмәгән, әлбәттә.

Анысы инде хәзинәдә бары белән... Кешеләр үзләренең шул бер катлы гади генә тормышларында, шул үз тирәләрен чолгаган табигатькә, шул үгез, атларның көченә, шул терлекләрнең биргән ит, сөт, кымыз, майларына, йон-тиреләренә турыдан-туры бәйле булып яшәгәннәр. Белмим, анда кешеләр атны җиккәнме, әллә кайчагында ат кешеләрне җиккәнмедер. Алай да малайлар, сыерга ук атланмасалар да, атына атланып рәхәтен күргәннәр, олылар да атта, арбаларда инде. Кешеләр шул терлекләр биргән ит, сөт һәм шул маллар көче белән үстерелгән игеннәргә турыдан-туры тоташып, үзләре дә табигатьләшеп, бер-берсенең хәлләрен белеп, вакыты белән гаиләдәгечә, үзара әйткәләшеп, типкәләшеп, тагын татуланышып, һаман катыш-кара бергә торганнар, ничек тә үзара бер-беренең хәлен якыннан аңлап, тоеп, җырда, сүздә шул хәлләрен бер-берләре белән уртаклашып, әйтеп, сызгырышып, җырлашып яшәгәннәр. Күрәсең, анда эшләр, чынлап та, Тукай әйткәнчәрәк, тавыклар да җырлый булган, сайрамый ләбаса, кычкырмый да, көйләми дә, ә җырлый. Инде тагы яшен ату, су басу, ут чыгу кебек көтелмәгән бәла-каза, стихияләр килсә, анда да тагы әллә кая телеграммалар сугу, телефоннар шалтырату юк, тагын шул ук табигатькә сыенганнар. Ә инде тулысы белән кояш тотыла калса, анда эш бөтенләй дә харап; бөтен табигатькә, бөтен галәмгә зур һәлакәт килгән кебек кешеләр хайваннары белән бергә үкереп елашканнар, барлык кылган гөнаһ-җинаятьләре искә төшеп, шулар шомлыгыннан тотылган көн

алдында тәүбәләр әйтелгән. Инде кояш шул тотылуыннан ачыла башласа, бу кешеләр тәүбәләре «кабул булуга» тагын балалар кебек куанып, бер-берләрен котлаша башлаганнар.

Хәзер бу әйткәннәребездән соң, тагын «Коңгыр бога»га килсәк, аның белән дә шундый ук хәл. Уен эшмени? Әнә бит, әнә, нәсел башы итеп саналган «үгез углы яшь бога» үзенең төп ата йортыннан язган! (Ә үгез – онытмыйк, бәлки, бу борынгы кешеләр өчен нәсел башы – тотемдыр?. – *Н.И.*)

Ана карынында башы чит җирләргә олагып, анда туып калган. Шуннан менә шул безнең үгез углы «коңгыр бога» анда үзенең ата йортын сагынып, менә инде йөрәгенә түзми ярсып, тояклары белән җирне казый, исни, күзеннән мөлдерәп яшьләр ага икән, ди... Җир ертып үкереп, кинәт-кинәт үзен-үзе җирләргә ата, тагын җылый икән, ди. Шуннан менә ул үзенең төп ватанын, ата йортын эзләп юлга чыккан. Сорашыр теле юк, алай да күңеле сизә мәхлукның, әнә ни кадәр җәфа-михнәтләр чиксә чиккән, кайткан бит! Ата йортын үзе эзләп, үзе искәп тапкан, үзе кайткан[6]. Юк, юк, бу тикмә бер эш кенә түгел, гадәттән тыш бер хәл. Менә шул могҗизалы хәлне ишетеп, әнә бүген бөтен ил купмыйча хәле бармы? Бар да шушы гадәттән тыш боганы, бу тамашаны үз күзе белән күреп калырга мәйданга ашыга. Бар да моны олы хикмәтле вакыйга итеп кабул итә. Җырчы-җыраулар, көйчеләр җыелып, бу «муенчагын сөйрәткән, сыртын кемгә көйрәткән» ягъни әсирлек муенчагын муеныннан өзеп салып, үз йортының ирекле көч һәм ихтыяр гәүдәләнеше булып алларына килеп баскан боганың ниләр-ниләр күргәнен алар хәзер әнә җырга, думбрага салып, кыйссасын дастан итеп әйтеп җырлыйлар. Тын калып тыңлаган кешеләр моны ишетеп, табигатьтәге бу гаҗәп хәлдән хәйран калган. Үзләре дә әсәрләнешеп елыйлар.

Шуннан инде бу заман кешесе сизенә дә җавап биреп чыта:

- Юк, абзый, ул «Коңгыр бога» дигәнең [...] тау сыртына үзе менеп, ата йортын үз күңел хисе, үз танавы белән сизеп, үз ирке белән шуны эзли чыгып, кеше белмәс юллардан үзенә-үзе юл сабып, кайтып килгән «Коңгыр бога» булыр beләсең килсә.

Бу тантаналы, әсәрле, тотемистик җырлар, бу дастан, бу мактау-мәдхия, гимннар астында бога шәрәфенә ясалган мондый мәйданнарда ул иске заманнарда, әлбәттә, корбан чалынмыйча, казаннар асылмыйча, һавага төтеннәр күтәрелмичә булмый. Инде туен туйлап, сыен сыйланып, мәҗлес күңел ачуга күчкәндә, әлбәттә инде, әлеге «Илче бага» кебек шатлыклы, җиңел, кыска җырлар башлангандыр. Һәм такмак әйтеп биюләр киткәндер. Элек җыр, көй, бию бер-берсеннән аерылмаган заманда, мондый зур вакыйга шундый бәйрәм йоласыз уздырылмый. Мөгаен, бу юлы да шулай булгандыр...

Хис йогышлы әйбер, ләкин «коңгыр бога»ны кешеләр анда шулай турыдан-туры һәм катлаусыз хис итсәләр дә, алар аны, әлбәттә инде, бөтенесе берьюлы, бер сискәнү, йә бер курку кичергән көтү хайваны кебек, бар да бердәй, аермасыз, төп тоташ бер генә төр кичергәннәр дип уйларга ярамый. Кеше бит ул үзе күмәкчел булса да, шул ук вакыт һәркайсының үз күзе, үз хәтер кичереше яки «үз манарасы» кичереше, үз түбәсе, «манарасы», ягъни үз тамашасы бар.

Әйтик, анда берәресе, ата-бабасыннан ишетмеш буенча, борынгы төрки халыкларның ерак төп бабалары «Угыз хан» исемле булган дип белгән һәм үз ыру бабасы да үгез /тотем/ булган дип йөри. Хәзер шул мифик иманлы борынгы кешебез бу ата йортын эзләп кайтучы «Коңгыр бога»да нәрсә күрер? Әлбәттә инде, шул үзе мөкатдәс тотем дип белгән үгез рухының чагылышын, җанлы шаһитын, шул рухның үз төп ата йортын эзләвен күрә. «Коңгыр бога»да шул ата рухының, ватан мәхәббәтенең тере гәүдәләнешен күреп әсәрә, аңа хәзер бу башмак үгез – Алла урынында изге бер күренеш. Икенче берәүләре исә, «Коңгыр бога»ны моннан элек шушы ватан җирләрен басып алучы берәр яу кулында үтерелгән ханның берәр зур кабилә башлыгының ятлар кулына әсир төшкән бикәсе карынында китеп читтә туган углы белән чагыштыра: «Коңгыр бога» төсендә шул бәк углының үз җир-суын, илен, ватанын, сагынып кайтуының гәүдәләнеше кебек бер хәл хис итә, шуңа хәйран. Күрәсез, монда һәркем безнекенә башка дөньяда яши, бу аның үз дөньясы, бу галәм аның үз тарихи җәмгыятенең тормышы һәм риваятьләр ассоциациясе галәме. Син аның ул мәйдан тоткан җирен тапсаң да, аның ул

[6] Уралда башкортлар, үз сүзләренә дәлил итеп, «Коңгыр бога» эзе яки юлы дигән тау өсиләп, озын бер юл күрсәтәләр. Имеш, бу озын юл бер кая да кичү-елгалар аша үтми, шулай итеп башмак үгез беркайда да тоягына су тигезми кайткан... – *Н. Исәнбәт искәрмәсе.*

галәменә бернинди археологик казылмаларың белән дә керә алмыйсың. Керәсең икән, ул да шул борынгыдан калма «Коңгыр бога» кебек җыр-көй әсәре аша берәр көрәк җир булса да, казып кына керә алырсың, күңел колагың салсаң, бәлки әле андагы һай-һой авазларын да ишетерсең. Курәсең, ул тарихи кеше анда безнекенә башка форма үз дөньясында яши, башка төрле хисләр, башка дәртләр һәм хәтер ялкыннары белән яна. Менә ни өчен дә анда ул кешеләр «Коңгыр бога»ны күргәндә, кайсы көлә, кайсы җылый яки бии. Менә ни өчен җыраулар аңа думбра чалып, мактау дастаннары җырлый, аның бу изге юлда җан фида итеп, бернинди аю-бүредән дә, кешедән дә курыкмыйча, үз төп җирен эзләп кайтып килүен, үз тияген[7] табуын мактый. Менә ни өчен берләре шул данлы боганың муенын кочып җылый, күпне күргән әбиләр исә, ул мөбарәк хайванга күз тимәсен өчен, нидер укыньп, муенына ефәк чуклар, көмеш галәмәтләр, кортбашлар тагалар. Шулай итеп, башмак үгез күрә торып күз алдында дастан каһарманына әйләнә. Бөтен мәйдан аны котлап, «Коңгыр бога», һау-һәү!...не әйтеп җырлый.

### Нәтиҗәләр

Шулай итеп, минемчә, бу иске, матур «Коңгыр бога» көе халыкка борынгы табигый, тирән ватанчылык хисенең үзенчәлекле, стихиячел пәйда булышыдыр. Шул ук вакыт борынгы кешенең җыр-көй, фольклор иҗаты стихиячел һәм илһами (импровизацион. – *Н.И.*) булса да, монда онытмыйк, һәркемнең үз шәхесе кичереше, үз түбәсе яки «үз манарасы» бар. Монда исә бу көй – бу җырда, бу легенда һәм бу «Коңгыр бога» йоласында. Аларны бергә җыйган, җырлаткан нәрсә исә, барына да хәтта, хайваннарга да уртак булган бер хис тәкъбир ителә, ул да булса, җирсенү, ватанчылык хиседер, барысына да табигый һәм изге булган ватанчылык хиседер. Монда шул әйтелә, һәм бу җыр-көйнең зур тәэсир итү көченә ия, үзенчәлекле шәп музыкаль әсәр булуының сере дә шунда.

Бу үгез легендасына бәйләнешле җыр яки башка хәбәрләр каһарманы Уралда «Коңгыр бога», башкортчада «Куңгыр буга» һәм «Ҡуңыр буға», «Коңор бого», Иртышта «Илче бага» исемләнсә, Чулман-Камада ихтимал ул «Ала буга» яки башка берәр төрле аталгандыр. Идел – Уралда «Бугырслан» / Буга арыслан?/ яки «Богавы» кебек җир-су, кала-сала исемнәре дә аз түгел бит. Тагын да борын-борынгарак китсәк, бу якларда болан-пошилар көтү-көтү булып иркен йөргән заманнардан калма йолаларга бәйле яклары да килеп чыгу ихтимал. Болан үгезе дә «бугу» дип аталган бит. Ә инде пошига килсәк, аның безнең халыкта, шушы соңгы заманнарга кадәр кагылырга-тияргә ярамый торган изге табу итеп саналуы, аны тоткан-аткан кешеләрне әрләп-хурлап бөтен илгә фаш иткән бәетләрдән дә күренеп тора.

### Йомгак

Билгеле, «Коңгыр бога»ның хәзер анда-монда теге-бу хәбәре, кисәкчә кайбер җырлары, көйләре саклanса да, аның хакындагы борынгы дастан [...] онытылган. Бу гаҗәп көйне тыңлаганда, анда нәрсә хакында сүз баруын, инде - нинди *һау-һау*лар әйтелүен, аның эт өрүеме, яки иркәләү *һәү-һүе* икәнен тыңлаучылар да түгел, җырлаучылар да аңламый җырлый икәнлекләре күренеп тора. Билгеле, җырны бит аны үзен, мәгънәсен аңлап та, аңламыйча, сүзләрен корыга көйләп кенә дә «җырлап» була. Шулай булса да, берни дә аңламыйча, корыга җырлауга караганда, көйнең легендасын, тарихын, сүзләренең мәгънәсен төшенеп җырлаганда, күп мәртәбә реальрәк һәм әсәрлерәк булыр иде. Аннары мондый бай тамашалы, сюжетлы, йолалы көйләрдән оста режиссер, дирижер, җыр-хор җитәкчеләре белеп файдаланганда, әллә ни хәтле бай тамаша, манзаралар, кызыклы-күмәк уен, бию яки башка берәр детальләр белән баета алган булыр иде. Хәзерге хор, хореография, үгезле-мөгезле маскалар һәм халык үзешчән иҗатчылыгы бу мондый җырларны тантаналы мәйдан – җыр тамашасы фонында сурәтләүгә бөтен мөмкинлекләрне бирә.

**Әдәбият**

1. *Исәнбәт Н.* «Коңгыр бога» // Н. Исәнбәт шәхси архивыннан. Кульъязма. Машинкада басылган. 1968 ел. 11 б.
2. «Коңгыр бога» // Татарстан радиосы фондыннан. Дирижер һәм хормейстер: Җәвит Котдусов. 1968 ел. 3 мин. 24 сек.
3. Нәкый Исәнбәт. / Төз. М. М. Хәбетдинова. Казан: «Җыен» фонды нәшр., 2021. 736 б.
4. Иҙеүкәй менән Мораҙым. Тарихи ҡобайыр. Өфө: Башҡортостан «Китап» нәшриәте, 1994. 352 б.

[7] тияк – диалекталь сүз; күчерелмә мәгънәдә туган җирне, туган туфракны белдерә. – *Т.Г.*

5. Idukəj həm Moradum // Коммуна. 1940. № 78 (1477). 28 апрель; 79 (1478) 29 апрель.

6. Матбугат, әдәбият, халык иҗаты. ВКП(б) өлкә комитетының секретаре иптәш Аношинның Башкортстан партия оешмасының XX өлкә конференциясендә сөйләгән докладыннан // Октябрь. 1940. №5. 9 б.

7. *Шакуров Р. З.* «Куңыр буга» // Башкирская энциклопедия. Т. 3. Уфа: Научное изд-во «Башкирская энциклопедия», 2007. С. 605.

8. *Хамитова Г. Ч.* «Куңыр буга» // Башкирская энциклопедия. Т. 3. Уфа: Научное изд-во «Башкирская энциклопедия», 2007. С. 605.

9. *Батыршин Р. Р.* Сибирские татары // Татарская энциклопедия. Т. 5. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. С. 313–315.

---

# ПЕСНЯ «КОҢГЫР БОГА» («КОРИЧНЕВЫЙ БЫЧОК»): ИСТОРИЧЕСКИЕ КОРНИ И ПОЭТИКА В КОНТЕКСТЕ КУЛЬТУРЫ ТЮРКСКИХ НАРОДОВ[1]

**Наки Исанбет**,
Казань,
mileuscha@mail.ru.

Объектом изучения в данной статье являются дастан «Коңгыр бога» («Коричневый бычок») и одноименная башкирская народная песня. Предметом исследования стали история создания этих произведений, их идейно-эстетическое, жанровое своеобразие и связь с культурным наследием тюркских народов. Данный источник из архива Н. Исанбета впервые вводится в научный оборот. В этом состоит новизна данной работы. Дастан и башкирская песня «Коңгыр бога» исследуются в контексте взаимосвязи песни, музыки и устного народного творчества тюркских народов. Доказано, что история возникновения этих источников базируется на представлениях древних людей о мире и явлениях в нем, на мифологии, легендах, эпосах. Н. Исанбет обращает внимание не только на глубину семантики, эмоциональной силы, заложенной в песне «Коңгыр бога», но и на диалектическую взаимосвязь содержания с формой, особенностями исполнения песни. Автор статьи раскрывает национальные особенности звучания этих текстов, акцентирует внимание на чувстве патриотизма народа, что отражено в столь древних произведениях фольклора.

**Ключевые слова**: песня, мелодия, тюркские народы, культурные взаимосвязи, «Коңгыр бога», эпос, легенда, патриотическое чувство

[1] Статья хранится в личном архиве Наки Исанбета. В оригинале статья называется «„Коңгыр бога“ (О проявлении дружбы народов в музыке родственных народов)». Оформление статьи приведено в соответствие с правилами редактором журнала «Tatarica» Т. Ш. Гилазовым [1]. Автором научных комментариев, материалы для которых почерпнуты из научных работ Н. Исанбета и других ученых, является редактор журнала «Tatarica» М. М. Хабутдинова.